КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 август г.Казань № 683

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү турында» 2022 ел, 9 август, 778 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү турында» 2022 ел, 9 август, 778 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «2018 ел, 11 июнь,» сүзләрен «2018 ел, 11 июль,» сүзләренә алмаштырырга, «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» сүзләрен «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның унбишенче абзацында «яшьләрнең» сүзеннән соң «һәм яшь хезмәткәрләрнең» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин